Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XI-5**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 31 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерүгә юнәлдерелгән экспериментлар оештыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсе, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 41 маддәсе, Татарстан Республикасы Президентының “Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтен үстерүгә юнәлдерелгән экспериментларны оештыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 2021 елның 10 июнендәге ПУ-475 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерүгә юнәлдерелгән экспериментлар оештыру тәртибе турында кушымта итеп бирелә торган Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерүгә юнәлдерелгән экспериментлар оештырганда әлеге карарга таянып эш итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Советының 2021 елның
31 августындагы XI-5 номерлы
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерүгә юнәлдерелгән экспериментлар оештыру тәртибе турында Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәтне оештыруга яңа алымнар куллану һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеген тәэмин итү буенча экспериментлар (алга таба – экспериментлар) оештыру тәртибен, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органында (алга таба – җирле үзидарә органы), аның мөстәкыйль структур бүлекчәсендә экспериментлар үткәрүгә таләпләрне билгели.

2. Экспериментлар түбәндәге максатларда үткәрелә:

җирле үзидарә органнары эшчәнлеген планлаштыру һәм финанслауның яңа методларын үз эченә алган заманча идарә технологияләрен апробацияләү (сынап карау) һәм гамәлгә кертү, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының кадрлар составын булдыру (алга таба – муниципаль хезмәт) һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеген стимуллаштыру (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр);

муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри хезмәт эшчәнлеген бәяләү күрсәткечләрен һәм критерийларын апробацияләү (сынап карау) һәм гамәлгә кертү;

хезмәт хакын камилләштерү һәм муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеген регламентлаштыру;

муниципаль хезмәтнең финанс-икътисадый һәм матди-техник тәэмин ителешен камилләштерү;

җирле үзидарә органының структурасын һәм штат санын оптимальләштерү;

муниципаль хезмәткәрләрне әзерләү һәм һөнәри үстерү системасын камилләштерү;

мәгълүмати-коммуникация технологияләрен кулланып кадрлар эшен гамәлгә ашыру ысулларын апробацияләү;

муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан һөнәри хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруның дистанцион формасын апробацияләү;

муниципаль хезмәт үсеше һәм муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри хезмәт эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру белән бәйле башка максатларга ирешү.

3. Экспериментлар үткәрү тәртибе, шартлары һәм сроклары, шулай ук аларны үткәрү турында йомгаклау хисапларын бирү тәртибе һәм сроклары җирле үзидарә органнарында, аларның мөстәкыйль структур бүлекчәләрендә экспериментларга карата Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгының эксперимент уздыру турындагы акт проекты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлеге тарафыннан үз инициативасы белән дә, эксперимент үткәрү планлаштырыла торган җирле үзидарә органы тәкъдимнәре нигезендә дә муниципаль норматив хокукый актларда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә әзерләнә һәм түбәндәгеләрне үз эченә алырга тиеш:

тәҗрибәне үткәрү тәкъдим ителә торган җирле үзидарә органының, аның мөстәкыйль структур бүлекчәсенең аталышы;

экспериментның максатларын, бурычларын һәм эчтәлеген тасвирлау;

экспериментны үткәрү сроклары;

экспериментны финанслау чыганаклары.

Экспериментны берничә җирле үзидарә органында үткәрергә тәкъдим ителгән очракта, акт проектында шулай ук әлеге органнарның исемнәре күрсәтелә һәм әлеге җирле үзидарә органнарының кайсысы эксперимент координаторы булачагы билгеләнә.

5. Экспериментны уздыруга бәйле чыгымнарны финанслау Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетында тиешле җирле үзидарә органнарын тотуга каралган бюджет ассигнованиеләре исәбеннән һәм шулар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

6. Эксперимент җирле үзидарә органында, аның мөстәкыйль структур бүлекчәсендә җирле үзидарә органы җитәкчесе (эксперимент координаторы булган орган җитәкчесе) тарафыннан раслана торган план-график нигезендә эксперимент үткәрү турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы акты үз көченә кергән көннән алып 20 көн эчендә уздырыла.

7. Әлеге Нигезләмәнең 6 пунктында каралган план-графикта түбәндәгеләр күрсәтелә:

эксперимент үткәрү сроклары һәм рәвешләре;

эксперимент үткәрү этаплары һәм һәр этапның көтелгән нәтиҗәләре;

тәҗрибәнең нәтиҗәләренең дөреслеген тикшереп тору һәм тәэмин итү чаралары;

эксперимент нәтиҗәләре буенча тулаем алганда хисап рәвешләре һәм аның һәр этабы буенча аерым алганда;

һәр этапта экспериментны кадрлар, икътисадый, матди-техник һәм фәнни яктан тәэмин итү буенча мәгълүматлар;

эксперимент үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат, шулай ук экспериментның һәр этабын үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затлар;

эксперимент үткәрүнең көтелгән нәтиҗәләре.

8. Муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль хезмәткә керүче Россия Федерациясе гражданнарының экспериментта катнашуы ирекле рәвештә гамәлгә ашырыла.

9. Эксперимент үткәрү чорында, әмма Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән тәртиптә бер елдан да артмаган вакытта, экспериментта катнашучы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт контрактлары шартлары үзгәрергә мөмкин.

10. Эксперимент үткәрү чорында экспериментта катнашучы муниципаль хезмәткәрнең хезмәт контракты шартларын үзгәртү яклар килешүе буенча һәм язма рәвештә гамәлгә ашырыла. Хезмәт контракты шартларын үзгәртү, эксперимент башланганда аңа акчалата түләү белән чагыштырганда, экспериментта катнашучы муниципаль хезмәткәрнең - экспериментта катнашучының акчалата күләме кимүгә, шулай ук әлеге муниципаль хезмәткәрнең эксперимент башланган вакытта биләгән вазыйфасы белән чагыштырганда вазыйфасында түбән төшүгә китермәскә тиеш.

11. Җирле үзидарә органында эксперимент үткәрү өчен җаваплы итеп җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасарыннан да ким булмаган муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торучы вазыйфаи зат билгеләнә, ә эксперимент берничә органда үткәрелгән очракта, аларның һәркайсында җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасарыннан да ким булмаган муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче вазыйфаи зат эксперимент үткәрү өчен җаваплы булып билгеләнә.

Җирле үзидарә органының мөстәкыйль структур бүлекчәсендә эксперимент үткәрү өчен җаваплы итеп җирле үзидарә органының мөстәкыйль структур бүлекчәсе җитәкчесе урынбасарыннан ким булмаган муниципаль хезмәт вазыйфасын биләп торучы вазыйфаи зат билгеләнә.

12. Эксперимент уздыру өчен җаваплы вазыйфаи зат, җирле үзидарә органының (эксперимент координаторы (яраштыручысы) булган органның) тиешле акты нигезендә:

эксперимент үткәрүнең арадаш планнарын раслый һәм аларның үтәлешен контрольдә тота;

эксперимент үткәрүнең кирәкле оештыру, методик һәм матди шартларын тәэмин итүне гамәлгә ашыра.

13. Экспериментның барышы һәм нәтиҗәләре турында мәгълүмат Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “кадрлар сәясәте” бүлегендә урнаштырыла.

14. Җирле үзидарә органында (җирле үзидарә органнарында), аның мөстәкыйль структур бүлекчәсендә эксперимент тәмамланганнан соң 30 көн эчендә эксперимент үткәрү турында йомгаклау хисабы җирле үзидарә органы җитәкчесе (эксперимент координаторы булган орган җитәкчесе) тарафыннан раслана һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгына тәкъдим итү өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә җибәрелә.

15. Эксперимент үткәрү турында йомгаклау хисабы үз эченә ала:

эксперимент үткәрү барышында гамәлгә ашырылган чаралар тасвирламасы;

эксперимент барышында ирешелгән максатлар һәм хәл ителгән бурычлар турында белешмәләр;

җирле үзидарә органнарында экспериментның уңай нәтиҗәләрен куллану мөмкинлекләре, тәртибе һәм формалары турында мәгълүматлар;

эксперимент нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәтне норматив-хокукый җайга салуны камилләштерү турында тәкъдимнәр;

эксперимент нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәтнең нәтиҗәлелеген арттыру турында тәкъдимнәр;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының эксперимент үткәрүгә тотылган бюджеты акчалары турында мәгълүматлар.

15. Эксперимент нәтиҗәләрен куллануның максатка ярашлы булуы турындагы карар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башлыгы тарафыннан кабул ителә.